**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**Сарманавылжирлеге**
**423350 Сарманавылы, М.Жэлилур., 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E - mail: Sar.sar @ tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

**Сармановское сельское поселение**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423350 с. Сарманово, ул.М.Джалиля, 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: Sar.sar @ tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20 февраля 2023 года № 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карар проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм кайбер актларның аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» 2022 елның 20 апрелендәге 711 номерлы карары, «Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында» 2021 елның 06 маендагы 5 номерлы Сарман авыл җирлеге Советы карары, Сарман авыл җирлеге Советының 2021 елның 27 декабрендәге 37 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында проект буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Билгеләргә:

- гавами тыңлауларны оештыручы - Сарман авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе;

- гавами тыңлаулар үткәрү вакыты - 2023 елның 22 мартында 14 сәгатьтә;

- үткәрелү урыны - Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Сарман киноучреҗдениесы конференцзалында (Сарман ав., Ленин ур., 28).;

- адрес буенча фикер алыша торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелергә мөмкин - Куйбышев 31а урамы, Сарман авыл җирлеге

башкарма комитеты (эш көннәрендә 8.00 дән 16.00 сәгатькә кадәр (төшке ашка тәнәфес 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).

4. Сарман авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проектын әзерләү комиссияләре:

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы проект буенча гамәлдәге законнар нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән вакытларда гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

- гавами тыңлаулар уздыру нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

5. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» һәм http://pravo.tatarstan.ru һәм веб-адрес буенча Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөклим.

Татарстан Республикасы

Сарман муниципаль районы

Сарман авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Хөснуллин

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районының
Сарман авыл җирлеге
башлыгының 20___ елның
_________ ___ номерлы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү**

35 статьяның Индивидуаль торак төзелеше зонасы, «Күчемсез мөлкәтне кулланунын төп төрләре» шәһәр төзелеше зоналары картасында билгеләнгән территориаль зоналар төрләре. 11 бүлекнең Ж-1 абзацында өстәргә:

«- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен

- яшелчәчелек алып бару

- бакчачылыкны алып бару

- печән чабу

- терлекчелек

- автотранспортны саклау

- коммуналь хезмәт күрсәтү

- элемтә хезмәтләре күрсәтү

- көнкүреш хезмәте күрсәтү

- сәламәтлек саклау

- белем бирү һәм мәгариф

- мәдәни үсеш

- мәдәният һәм ял паркы.

- дини файдалану

- иҗтимагый идарә

- ветеринария хезмәте күрсәтү

- эшмәкәрлек

- кибетләр

- җәмәгать туклануы

- кунакханә хезмәте күрсәтү

- юл сервисы объектлары

- ял

- спорт

- гидротехник корылмалар

- урам-юл челтәре

- ритуаль эшчәнлек»

СХ-1 абзац. Торак пунктлар чикләрендә авыл хуҗалыгы җирләре зонасы, «Күчемсез мөлкәтне рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре» бүлегенә түбәндәге сүзләр өстәргә:

«-авыл хуҗалыгы куллануы»

СХ-2 абзац. Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар зонасы, «Күчемсез мөлкәтне рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре» бүлегенә өстәргә:

«-авыл хуҗалыгы куллануы»

Гражданнарга милек буларак бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик күләмнәрен (максималь һәм минималь) билгеләргә:

- Бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен 0.0015 тән 0,25 гектарга кадәр